ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2024 п.г.т.Алексеевское № 523

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Административ комиссиясе турында**

Алексеевск муниципаль районы Советының 07.10.2024 ел, № 270 «Алексеевск муниципаль районының административ комиссиясе турында» карарына туры китереп һәм «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Административ комиссиясенең эш регламентын (1 нче кушымта) расларга.

2. Административ комиссия составын расларга (2 нче кушымта).

3. Башкарма комитетның 01.02.2021 ел, № 29 «Административ комиссия турында», 17.11.2022 ел, № 498 «Башкарма комитетның 01.02.2021 ел, № 29 «Административ комиссия турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында», 30.05.2023 ел, № 191«Башкарма комитетның 01.02.2021 ел, № 29 «Административ комиссия турында» карарларына үзгәрешләр кертү турында», 19.07.2023 № 256 «Башкарма комитетның 01.02.2021 № 29 «Административ комиссия турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
__27.11.2024_№__523__
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Административ комиссиясенең эш регламенты**

Алексеевск муниципаль районы Административ комиссиясенең эш регламенты (алга таба - Регламент) Алексеевск муниципаль районы Административ комиссиясе (алга таба - Административ комиссия) эшчәнлегенең эчке мәсьәләләрен, шул исәптән утырышлар алып бару, комиссия әгъзалары арасында эшне бүлү тәртибен билгели.

Әлеге Регламент таләпләре Административ комиссия эше өчен мәҗбүри.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Алексеевск муниципаль районы Советының 07.10.2024 ел, № 270 «Алексеевск муниципаль районының административ комиссиясе турында» карары нигезендә төзелде.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм шәһәр һәм авыл җирлекләрен төзекләндерүне белән тәэмин итү өлкәсендәге башка муниципаль норматив хокукый актлар,әлеге Регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары административ комиссияләр төзиләр һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итәләр.

1.4. Административ комиссиянең вәкаләтләр чоры комиссиянең беренче утырышы көненнән алып 5 ел тәшкил итә.

1.5. Административ комиссия административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.6. Административ комиссияне төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Алексеевск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенция бирелә.

1.7. Административ комиссияне төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы гамәлгә ашыра.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатибеннән һәм әгъзаларыннан тора.

2.2. Рәис Административ комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

2.3. Административ комиссия эшен оештыруда шулай ук рәис урынбасары, җаваплы секретарь, комиссия әгъзалары һәм вазыйфаи затлар катнаша.

2.4. Комиссиянең җаваплы секретаре даими нигездә эшли.

2.5. Административ комиссия әгъзалары саны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан 7 кеше итеп билгеләнә.

2.6. Комиссия әгъзалары Административ хокук бозу турындагы эшне караганда тигез хокукларга ия.

2.7. Административ комиссиянең барлык әгъзалары да югары белемле булырга тиеш.

2.8. Административ комиссия үз эшчәнлеген гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашыра. Административ комиссиянең агымдагы эше рәис раслаган план буенча алып барыла.

2.9. Административ хокук бозулар турындагы эшне башкаруга кабул иткән җаваплы секретарь аларны Административ комиссия утырышында карауга тиешле әзерлек уздыра.

2.10. Административ комиссиядә билгеләнгән форма буенча статистик хисап алып барыла.

Статистик белешмәләр ай саен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча тапшырыла.

Әлеге хисапларның нигезе булып Административ хокук бозулар турындагы эшләрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне беренчел исәпкә алу тора.

Статистик хисапны дөрес һәм үз вакытында тапшырган өчен җаваплылык Административ комиссия рәисенә, ә ул булмаганда - аның урынбасарына йөкләнә.

2.11. Законнарда каралган очраклардан тыш, мөрәҗәгать итүчеләргә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карар чыгарганчы бирү тыела.

## 3. Утырышны алып бару тәртибе

3.1. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия

утырышларында рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь, комиссия әгъзалары, эштә катнашучы башка затлар һәм аларның вәкилләре составында карала.

Комиссия утырышлары административ хокук бозулар турында эшләр булганда атна саен уздырыла. Утырышның датасы һәм вакыты турында комиссия әгъзаларына һәм аңа карата административ эш алып барыла торган затка утырыш уздыру көненә кадәр 2 көн кала комиссия секретаре хәбәр итә.

3.2. Утырышта Административ комиссия рәисе, ә ул булмаганда - аның урынбасары рәислек итә.

3.3. Административ комиссия утырышлары ачык була. Аларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша.

3.4. Административ комиссия карары буенча аның утырышлары ябык булырга мөмкин. Аларда комиссия әгъзалары, хокук саклау органнарының вазыйфаи затлары һәм махсус чакырылган затлар гына катнашырга хокуклы.

3.5. Утырышлар закон таләпләрен үтәгән килеш утырышлар залында уздырыла, ул булмаганда эшләрне башка биналарда карау рөхсәт ителә.

3.6. Административ комиссия утырышы аның составының кимендә өчтән икесе булганда хокуклы.

3.7. Комиссия әгъзалары Административ комиссия утырышларында алмаштыру хокукыннан башка катнашалар.

3.8. Административ комиссия утырышы вакытында Кино-, видео - һәм фотога төшерү рәис рөхсәте белән башкарыла.

3.9. Административ комиссия утырышын әзерләүне җаваплы секретарь гамәлгә ашыра, ул карауга билгеләнгән административ хокук бозулар турындагы эшләрнең исемлеген төзи, рәислек итүчегә аларны карау мөмкинлеге турында хәбәр итә, якның килүен һәм вәкилләрнең вәкаләтләрен, шулай ук өстәмә материаллар керүен тикшерә.

3.10. Административ хокук бозу турындагы эшне карау өчен билгеләнгән вакытта рәислек итүче утырышны ача, комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокукларын һәм бурычларын аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гаризалары, үтенечнамәләре булу-булмавын ачыклый, утырышка җитәкчелек итә, эшнең барлык шартларын тулысынча ачыкларга ярдәм итә, утырыш барышында тиешле тәртипнең үтәлешен тәэмин итә.

3.11. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау чираты хәбәрләр белән билгеләнә. Кирәк булганда Административ комиссия бу чиратны үзгәртергә хокуклы.

3.12. Административ хокук бозу турындагы эшне карау рәислек итүченең административ материалда бәян ителгән хәлләр турындагы докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң Административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.13. Рәислек итүче докладтан соң комиссия административ хокук бозу турындагы эшне тикшерүгә күчә, анда комиссия әгъзалары гына катнаша.

3.14. Административ комиссиянең һәр утырышында административ хокук бозу турындагы эшне карау турында беркетмә алып бару мәҗбүри, ул җаваплы секретарь тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.15. Административ хокук бозу турындагы эшне кичектереп тору, тәнәфес игълан итү һәм яңадан карау гамәлдәге законнар таләпләрен үтәгән килеш гамәлгә ашырыла.

## 4. Административ комиссия карары

4.1. Административ комиссия карары рәислек итүче тарафыннан имзалана.

4.2. Бер үк вакытта утырышта катнашучы затларга һәм аларның вәкилләренә Административ комиссия карарына шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

4.3. Карарның күчермәсе расписка белән физик затка яисә физик затның законлы вәкиленә яисә юридик затның законлы вәкиленә тапшырыла йә күрсәтелгән карар чыгарылган көннән алып өч көн эчендә күрсәтелгән затларга җибәрелә.

4.4. Административ комиссия карарларының күчермәләрен вакытында тапшыруны һәм җибәрүне тикшереп тору җаваплы секретарьга йөкләнә.

4.5. Законлы көченә кергән Административ комиссия карарын үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

4.6. Административ комиссия карарларына карата шикаятьләр йә протестлар административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

## 5. Административ җәза салу турындагы карарны үтәү

5.1. Административ хокук бозу турындагы эш буенча административ комиссия карары Барлык дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре, юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

5.2. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар ул законлы көченә кергән мизгелдән үтәлергә тиеш.

5.3. Административ штраф административ штраф салу турындагы карар законлы көченә кергән көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча йә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 31.5 статьясында каралган кичектерү яисә кичектереп түләү срогы чыккан көннән соң административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан түләнергә тиеш.

5.4. Административ штраф суммасы административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан банктагы яисә башка кредит оешмасындагы тиешле счетка кертелә яисә күчерелә.

5.5. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карарга шикаять карарның күчермәсен тапшырган яисә алган көннән алып ун тәүлек эчендә бирелергә мөмкин.

5.6. Административ штраф түләү турында таныклык бирүче документ булмаганда, карар законлы көченә кергән көннән соң утыз көн узгач, административ комиссия тиешле материалларны федераль законнарда каралган тәртиптә административ штраф суммасын түләтү өчен суд пристав-башкаручысына җибәрә.

### 6. Административ хокук бозуларны профилактикалау

6.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында Административ комиссия үз эшчәнлеген тикшереп тору органнары, федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

6.2. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эшне оештыра.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
__27.11.2024__№__523__
карарына 2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы**
**Административ комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| 1. Леденцов Олег Николаевич | комиссия рәисе, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2. Белова Галина Владимировна | комиссия рәисе урынбасары, Алексеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары (килештерү буенча) |
| 3. Хәмзина Елена Александровна | комиссия рәисе урынбасары, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 4. Плотникова Надежда Анатольевна | административ комиссиянең җаваплы секретаре |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| 5. Фомина Надежда Александровна | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| 6. Свистунов Игорь Константинович | Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |
| 7. Йосыпова Гөлсинә Әсәдулловна | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**